МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«10» апрель 2017 ел г. Казань № 746-р

**Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Тәкъдим ителгән Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр в.б** **С.А.Демидов**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
«10» апрель 2017 ел. № 746-р
карары белән расланды

**Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәтен күрсәтү) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: газ бүлү челтәрләренең милекчеләре яки эксплуатацияләүче оешмалар булган юридик затлар.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчеләр һәм гариза бирүче булган юридик зат исеменнән эш итүчеләр булып юридик затның җитәкчесе яки юридик затның вәкаләтле вәкиле (алга таба – гариза бирүчеләр) санала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – «Сукно бистәсе».

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлегенең белешмә телефоны (алга таба – Бүлек): 221-40-36, 221-40-37.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләренә урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2001, № 44, 4147 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль закон (алга таба – Закон № 69-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1999, № 14, 1667 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Кадастр эшчәнлеге турында” 2007 елның 24 июлендәге № 221-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2007, № 31, 4017 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, № 31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 29, 4344 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары (алга таба – № 878 Карар) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2000, № 48, 4694 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 4 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 0985 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, №37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында” 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 апрель, № 288 карары (алга таба – ПКМ № 288) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2014, № 36, 1116 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) дөреслеккә туры килмәвенә китерүче Министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Гаризаның киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

## 2. Стандарт предоставления государственной услуги

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү | РФ ҖК, 90 ст.;<br>Закон № 69-ФЗ, 28 ст;<br>№ 878 Карар;<br>ТР ҖК, 4 ст.;<br>ПКМ № 288;<br>Нигезләмә 3.3.82 п |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | ПКМ № 288;<br>Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында карар (алга таба – саклык зоналары чикләрен саклау турында карар).<br>Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар | РФ ҖК, 90 ст.;<br>Закон № 69-ФЗ, 28 ст.;<br>№ 878 Карар;<br>ТР ҖК, 4 ст.;<br>ПКМ № 288;<br>Нигезләмә 3.3.82 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт | Дәүләт хезмәте гариза һәм аңа беркетелгән документлар кергән көннән башлап, гаризаны карау вакытын туктатып торуны санамыйча, утыз көн эчендә күрсәтелә,<br>Гариза Тәртипнең 7 пунктына туры килмәү очрагында, шулай ук, Тәртипнең 8 пунктында | ПКМ № 288, 18 п;<br><br>ПКМ №288, 7, 8, 13, 14 п. |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүне туктату срогы | күрсәтелгән документлар тулы күләмдә тапшырылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торыла.<br>Дәүләт хезмәтен туктатып тору срогы – Гариза бирүче туктатып торуга нигез булган сәбәпләрне бетерә торган документларны күрсәткәнчегә кадәр, әмма аңа гаризаны карауны туктатып тору турында белдерү җибәрелгәннән соң 30 көннән дә артык түгел. | ПКМ №288, п. 14 |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү өчен гариза белән бергә түбәндәгеләр тапшырыла:<br>1. Саклык зоналары чикләре күләмнәренең исәп-хисаплары һәм нигезләве белән аңлатма язуы;<br>2. Газ бүлү челтәре объектына техник план (законнар нигезендә 2013 елның 1 январенә кадәр бирелгән техник паспорт);<br>3. Газ бүлү челтәре объектына хокук билгеләү документы;<br>4. Газ бүлү челтәре объектын төзүгә рөхсәтнамә (булса);<br>5. Газ бүлү челтәрен эксплуатацияләүгә шартнамә;<br>6. Расланырга тиешле саклык зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә хокук ияләренең хокуклары күрсәтелгән исемлек (проектлана | |

| | | |
|---|---|---|
| | торган газ бүлү челтәрләре өчен), аларның урнашкан урыны, кадастр номерлары, җир категорияләре һәм мәйданнары;<br>7. Газ бүлү челтәрләренең һәм аларның саклык зоналарының бердәм дәүләт яки җирле координаталар системасында эшләнгән һәм тиешле тәртиптә формалаштырылган башкару сурәте (башкару сурәте материаллары газ бүлү челтәрләре саклык зоналары турында белешмәләр составына кертелә, алар үз эченә әлеге зоналар чикләренең урнашу урынын текст һәм графика белән тасвирламаларын, күчемсез милек дәүләт кадастрын алып бару өчен билгеләнгән координаталар системасында әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталар исемлеген алырга тиеш);<br>8. Саклык зоналарының чикләре схемасын җир кишәрлекләренең милек ияләре, хуҗалары һәм файдаланучылары белән килештерелгәнлеген раслаучы документ (проектлаштырыла торган газ бүлү челтәрләре өчен);<br>9. Ышанычнамә (гариза бирүченең вәкиле гариза биргән очракта).<br>3 – 6 пунктларда күрсәтелгән документларны гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле), | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларны кабул итеп алучы Министрлык хезмәткәре тикшереп чыксын һәм расласын өчен күчермәләре белән бергә китерә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза белән мөрәҗәгать итүче үзенең шәхесен раслаган документ күрсәтә. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда саклanган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар саклanган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ);<br>Гариза бирүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль китерә ала.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән. | П.12 ПКМ № 288 |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерүләр таләп ителми. | ПКМ № 288 |

| | | |
|---|---|---|
| структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | ПКМ № 288 |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр:<br>гаризаның Тәртипнең 7 пунктына туры килмәве;<br>Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларның тулы күләмдә тапшырылмавы.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>Гариза бирүченең гаризаны карауны туктатып торуган нигез булган сәбәпләрне бетермәве. | п.13, п.14 ПКМ № 288<br><br><br><br><br>п.15 ПКМ № 288 |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Президент Указы РФ № 601, 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын регистрацияләү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка таләпләр | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазы һәм мәгълүмати стенд куелган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларга каршылыксыз керә алу, шул исәптән каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге белән тәэмин ителә, шул исәптән тиешле урынга килеп җитә алу максатында объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрәстелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү;<br>инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүматның булуы.<br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны | |

| | | |
|---|---|---|
| | бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә ике тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яисә телефоннан) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша белешә ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми. | |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күпфункцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләрне бетерү турында белдерү (хат) әзерләү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты әзерләү;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 3 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза регистрацияләнгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм регистрацияләү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән гаризаны Министрлыкка бирә.

Гариза һәм аңа беркетелгән документлар почта аша юллана ала.

3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече:

гаризаны һәм документларны кабул итеп ала;

гариза һәм аңа беркетелгән документларны регистрацияли һәм карау өчен Бүлеккә юллый;

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм бүлеккә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигез булган сәбәпләрне бетерә торган сәбәпләрне бетерү турында белдерү (хат) проекты әзерләү

3.4.1. Бүлек белгече гаризаны һәм документларны эш башкару бүлегеннән кабул итеп алганнан соң түбәндәгеләрне башкара:

әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр булу-булмавын тикшереп чыга;

андый нигезләр булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору тору турынңа белдерү (хат) проекты (алга таба – Бердерү) әзерли;

Белдерү проектын Бүлек мөдиренә килештерү өчен юллый.

3.4.2. Белдерү проектын карап чыга, килештерә һәм килештерү өчен җир ресурслары идарәсе башлыгына (алга таба - Идарә) юллый.

3.4.3. Идарә башлыгы Белдерү проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.4.1 – 3.4.3 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедурадан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган Белдерү проекты.

3.4.4. Бүлек белгече, Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән Белдерү проектын хокук идерәсенә юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, хокук идарәсенә юлланган Белдерү проекты.

3.4.5. Хокук идарәсе белгече Белдерү проектына хокукый экспертиза ясый, килештерелгән Белдерү проектын яки хокук идерәсе бәяләмәсе проектын (кимчелекләр булганда) килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.4.6. Хокук идарәсе башлыгы Белдерү проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый яки Белдерү проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.4.4 – 3.4.6 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Белдерү проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән Белдерү проекты.

3.4.7. Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алса, булган кимчелекләрне бетерә һәм Белдерү проектын яңадан хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.4.8. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне бетерү фактын тикшерә һәм тиешле Белдерү проектын килештерә.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган Белдерү проекты.

3.4.9. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлышы, хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән Белдерү проектын имзалау йчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы, хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән, министрның беренче урынбасарына юлланган Белдерү проекты.

3.4.10. Министрның беренче урынбасары Белдерү проектын имзалый һәм эш башкару бүлегенә регистрациягә юллана.

3.4.7 – 3.4.10 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедуралар тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары кул куйган, эш башкару бүлегенә регистрациягә юлланган Белдерү.

3.4.11. Белдерү юлланган гариза бирүче утыз көн эчендә дәүләт хезмәте күрсәтне туктатып торуга китергән сәбәпләрне төзәтергә, гаризаны Тәртипнең 7 пункты таләпләренә туры китерергә (туры килмәгән очракта) яки Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны тулы күләмендә (документлар тулысынча тапшырылмаган булса) тапшырырга хокуклы.

3.5. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр булмаса, Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр

(йөкләүләр) кертү буенча Министрлыкта гариза үтү битен тутыра (2нче кушымта) һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада запрослар юллый:

гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә бирү турында, ТР буенча ФСХИга.

Бу пункт билгели торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.2 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.5.2. Ведомствоара арадашлык органнары белгечләре ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән, әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында күрсәтелгән запрослар нигезендә тиешле срокларда соралган белешмәләрне (документлар) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар), яисә, соралган белешмәләрнең булмавы турындәа Министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.6. Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты әзерләү

3.6.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләр (документлар) алынганнан соң түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты (алга таба - Чикләрне раслау турында карар) әзерләү;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булып, Белдерү юлланган утыз көн эчендә алар төзәтелмәсә, саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты (алга таба – Баш тарту турында карар) әзерләү;

Чикләрне раслау турында карар проектын яки Баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар алдагы процедурадан соң алты эш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты.

3.6.2. Бүлек мөдире Чикләрне раслау турында карар проектын яки Баш тарту турында карар проектын карап чыга, килештерә һәм килештерү өчен җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

3.6.3. Идарә башлыгы Чикләрне раслау турында карар проектын яки Баш тарту турында карар проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.6.2, 3.6.3 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедуралар тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты.

3.6.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектын хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көндә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, хокук идарәсенә юлланган Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты.

3.6.5. Хокук идарәсе белгече Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый, хокук идарәсе бышлыгына килештерелгән Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектын, яисә хокук идарәсе бәяләмәсе проектын (кимчелекләр булса) юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгына юлланган кимчелекләр булган очракта язылган Чикләрне раслау турында карар проектына яки Баш тарту турында карар проектына хокук идарәсе бәяләмәсе проекты яисә килештерелгән Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты.

3.6.6. Хокук идарәсе башлыгы Чикләрне раслау турында карар проектын яки Баш тарту турында карар проектын килештерә яисә хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе бәяләмәсе яисә килештерелгән Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты.

3.6.7. Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган кимчелекләрне бетерә һәм Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектын яңадан хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.6.8. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең бетерелүен тикшерә һәм тиешле проектны килештерә.

3.6.7 һәм 3.6.8, пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедуралар тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән һәм Бүлек белгеченә юлланган Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты.

3.6.9. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы, хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проектын имза кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы, хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән һәм имза кую өчен министрның беренче урынбасарына юлланган Чикләрне раслау турында карар проекты яки Баш тарту турында карар проекты.

3.6.10. Министрның беренче урынбасары Баш тарту турында карар проектын имзалый һәм ул регистрация өчен эш башкару бүлегенә юллана, яки Чикләрне раслау турында карар проектын килештерә.

Әлеге пункт билгели торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары имзалаган һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә килештерелгән, министрга кул кую өчен юлланган Чикләрне раслау турында карар проекты.

3.6.11. Министр Чикләрне раслау турында карар проектын имзалый һәм ул регистрация өчен эш башкару бүлегенә юллана.

Әлеге пункт билгели торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кул куелган Чикләрне раслау турында карар.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә тапшыру.

3.7.1. Эш башкару бүлеге белгече Белдерүне яки Чикләрне раслау турында карарны яки Баш тарту турында карарны регистрацияли, гариза бирүчегә телефон аша Белдерүне яисә Чикләрне раслау турында карарны яки Баш тарту турында карарны тапшыру өчен билгеләнгән вакыт турында хәбәр итә яки гариза бирүче күрсәткән адрес буенча юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Эш башкару бүлегендә регистрацияләнгән, гариза бирүчегә юлланган Белдерү яки Чикләрне раслау турында карар яки Баш тарту турында карар.

3.7.2. Белдерү яки Чикләрне раслау турында карар яки Баш тарту турында карарны алу өчен вәкил килсә, документлар тапшыру буенча җаваплы белгеч түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен таныклаучы документны тикшерә; вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә) ачыклый;

Белдерү яки Чикләрне раслау турында карар яки Баш тарту турында карарны тапшыра һәм исәпкә алу кенәгәсенә документларның тапшырылуы турында язып куя.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган Белдерү яки Чикләрне раслау турында карар яки Баш тарту турында карар.

3.8. Дәүләт хезмәте электрон формада, күпфункцияле үзәкләр, күпфункцияле үзәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыны аша күрсәтелми.

3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү

Гариза бирүченең Чикләрне раслау турында карарда киткән техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

3.9.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

Чикләрне раслау турында карарның төп нөсхәсе;

техник хатаның булуын дәлилләгән документлар.

3.9.2. Чикләрне раслау турында карарда киткән техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча гаризаны гариза бирүче яки аның законлы вәкиле шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.9.3. Эш башкару бүлеге белгече гаризаны кабул итеп ала һәм, беркетелгән документлары белән бергә, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза һәм документлар тапшырылган (кергән) көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм регистрацияләнгән, карау өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза.

3.9.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм саклык зоналары чикләрен раслау турында карарга үзгәрешләр кертү максатыннан (техник хаталарны төзәтү) саклык зоналары чикләрен раслау турында карарга үзгәрешләр кертү проекты әзерли һәм әлеге Регламентның 3.6.1 – 3.6.11, 3.7.1 – 3.7.2 пунктларында каралган процедураларны күрсәтелгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар техник хата табылганнан соң яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан хата җибәрелү турында мөрәҗәгать алган көннән соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган Чикләрне раслау турында карарга әзерләнгән үзгәрешләр.

3.9.5. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документлар (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында гариза, Чикләрне раслау карарга кертелгән үзгәрешләр (техник хаталар төзәтелү белән бергә) Бүлек белгече тарафыннан Чикләрне раслау карарның Министрлыкта булган нөсхәсе янына беркетелә.

**4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары**

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен тикшереп тору юлы белән тормышка ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә тормышка ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча).

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актлар таләпләренең бозылуы алдарак ачыкланган булып, аларның төзәтелгәнлеген тикшерү өчен кирәк булганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре аркасында гариза бирүчеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуы турында шикаятьләр булганда.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә, Министрлыкның вазыйфаи затыннан яисә дәүләт хезмәткәреннән зарланып Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча министрның карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъекты норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъекты норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъекты норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү срогын яки тәнтибен бозганда;

9) Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатканда, әгәр андый туктату федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) Министрлык атамасы, аның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында белешмә;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булса), яисә аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.5. Шикаятькә анда күрсәтелгән шартларны раслый торган документлар теркәлә ала. Бу очракта теркәлгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне дәүләт хезмәте алучы имзалый.

5.7. Шикаять карап тикшерү вакыты – аны регистрацияләгәннән соң 15 көн. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә

5.8. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.9. Әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрына
(кемнән) ________________________________________
(оешманың оештыру-хокыйк формасы күрсәтелгән тулы һәм кыскартылган атамасы)
ИНН, ОГРН белешмәләре___________________________
Урнашу урыны ______________________________
Элемтә телефоны: ___________________________
Юридик һәм почта адресы _________________

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында
ГАРИЗА

Түбәндәге тасвирламаларга ия булган ____________________________________________________
(газ бүлү челтәрләре объекты атамасы)

басым_______________;
диаметр________________;
урнашу урыны _______________________________________________________________ (алга таба – ГРС объект)
газ бүлү челтәрләре объектын эксплуатацияләү шартларын тәэмин итү өчен газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында карар кабул итүегезне сорыйм.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен кәгазь документ рәвешендә:
а) шәхсән тапшыруыгызны;
б) кәгазь документ рәвешендә урнашка урынга җибәрүегезне (кирәклесенең астына сызарга) сорыйм.

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру

чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү үтенеч язуы имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Кушымта:

1. Саклык зоналары чикләре күләмнәренең исәп-хисаплары һәм нигезләве белән аңлатма язуы;
2. Газ бүлү челтәре объектына техник план (законнар нигезендә 2013 елның 1 январенә кадәр бирелгән техник паспорт);
3. Газ бүлү челтәре объектына хокук билгеләү документы;
4. Газ бүлү челтәре объектын төзүгә рөхсәтнамә (булса);
5. Газ бүлү челтәрен эксплуатацияләүгә шартнамә;
6. Расланырга тиешле саклык зоналары чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә хокук ияләренең хокуклары күрсәтелгән исемлек (проектлана торган газ бүлү челтәрләре өчен), аларның урнашкан урыны, кадастр номерлары, җир категорияләре һәм мәйданнары;
7. Газ бүлү челтәрләренең һәм аларның саклык зоналарының бердәм дәүләт яки җирле координаталар системасында эшләнгән һәм тиешле тәртиптә формалаштырылган башкару сурәте (башкару сурәте материаллары газ бүлү челтәрләре саклык зоналары турында белешмәләр составына кертелә, алар үз эченә әлеге зоналар чикләренең урнашу урынын текст һәм графика белән тасвирламаларын, күчемсез милек дәүләт кадастрын алып бару өчен билгеләнгән координаталар системасында элеге чикләрнең характерлы нокталары координаталар исемлеген алырга тиеш);
8. Саклык зоналарының чикләре схемасын җир кишәрлекләренең милек ияләре, хуҗалары һәм файдаланучылары белән килештерелгәнлеген раслаучы документ (проектлаштырыла торган газ бүлү челтәрләре өчен);
9. Ышанычнамә (гариза бирүченең вәкиле гариза биргән очракта).

   3 – 6 пунктларда күрсәтелгән документларны гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) тапшыра

3 – 6 пунктларда күрсәтелгән документларны гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле), документларны кабул итеп алучы Министрлык хезмәткәре тикшереп чыксын һәм расласын өчен күчермәләре белән бергә китерә.

Гариза бирүче(ләр) (вәкил(ләр)) ____________ № ____________ышанычнамә буенча
______________________________ /___________________/
(тулы вәкаләтле вәкилнең ФИӘИ (соңгысы - булса), имза)
М.П.(мөһер булса)

Гариза кабул ителде: «___»__________ 20__ ел.
_____________/____________________________________________/
имза (гаризаны алган белгечнең фамилиясе, инициаллары)

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча гариза үтү бите

Гариза бирүче ________________________________________________
Регистрация (керү) номеры _________________________

| N п/п | Министрлыкның структура бүлекчәләре | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Эш башкару һәм контроль бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 9. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны формалаштыру һәм регистрацияләү) | | | | |

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

**Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелеге**
**блок-схемасы**

Гариза бирүче (аның вәкиле)

Гариза бирүче (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге белән бергә гариза тапшыра (юллый)

Гариза, документлар

Эш башкару бүлеге белгече

Документларны кабул итү, гариза белән документларны регистрацияләү

Кабул ителгән, регистрацияләнгән, Бүлеккә юлланган документлар

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр булу-булмавын тикшерү

(туктатып тору өчен нигезләр булмау)
Гариза үтү бите тутырна һәм ТР буенча ФСХИга запрос юллый

Туктатып тору өчен нигезләр бар

ТР буенча ФСХИга запрос

Министрлык запросы буенча ТР буенча ФСХИ әзерләгән документлар

Бүлек белгече

Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты әзерли

Белдерү проекты әзерли

Бүлек мөдире

Белдерү проекты яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты

Белдерү проектын яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектын яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проектын карап чыга һәм килештерә

Килештерелгән Белдерү проекты яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты

Идарә башлыгы

Белдерү проектын яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектын яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проектын килештерә


Килештерелгән Белдерү проекты яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Килештерелгән Белдерү проектын яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектын яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проектын хокук идарәсенә юллый

Белдерү проекты яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш

Белдерү проектына яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектына яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында



Бәяләмә проекты (кимчелекләр булса), Килештерелгән Белдерү проекты яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты
Хокук идарәсе башлыгы
Бәяләмәне имзалый яки Белдерү проектын яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектын яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проектын килештерә
Имзаланган Бәяләмә яки килештерелгән Белдерү проекты яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты
Кимчелекләрне бетерә, проектны яңадак килештерү өчен җибәрә
Бүлек белгече
Белдерү проектын яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проектын имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юллый
Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектын килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый
Имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган Белдерү проекты яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проекты
Министрның беренче урынбасары
Килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юлланган Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проекты
Белдерү проектын яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар проектын имзалый һәм регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юллый
Министрның беренче урынбасары
Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектын килештерә һәм имза кую өчен министрга юллый
Белдерүне яисә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карарны яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карарны регистрацияли һәм гариза бирүчегә юллый
Министр
Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар проектын имзалый һәм регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юллый
Эш башкару бүлеге белгече
Гариза бирүчегә юлланган Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар
Гариза бирүчегә юлланган Белдерү
Имзаланган Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар
Гариза бирүчегә Саклык зоналары чикләрен раслау турында карарны яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карарны тапшыра
Гариза бирүчегә Белдерүне тапшыра
Гариза бирүчегә тапшырылган Саклык зоналары чикләрен раслау турында карар яки Саклык зоналары чикләрен раслаудан баш тарту турында карар
Туктатып торуга нигез булып торган шартларның бетүе
Гариза бирүчегә тапшырылган Белдерү

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

**Татарстан Республикасы**
**Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре**
**министрына**
(кемнән)_________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

Язылган:___________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
Дөрес белешмә:_______________________________________________________
________________________________________________________________________________

«____»_________ 20______ел №________ Чикләрне раслау турында карарда җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм тиешле төзәтмәләр кертүегезне сорыйм:

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында мәгълүматны язмача алырга риза

______________ _________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.ӘИ.(соңгысы - булса)

М.П.(мөһер булса)

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга кирә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
Кушымта (белешмәлек)

# Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау һәм аларга кирә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең өчен җаваплы һәм аны күрсәтүгә контрольлек итүче вазыйфаи затлар реквизитлары

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире<br>Садовникова Лариса Николаевна | 221-40-36 | larisa.sadovnikova@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты,
Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе мөдире<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |
| Идарә башлыгы урынбасары<br>Аксанов Валерий Аркадьевич | 264-76-89 | Valeriy.Aksanov@tatar.ru |